| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**Постановление** **Карар**

09.11.2018 Казан ш. № 10-31/кс

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2016 елның 9 декабрендәге 10-36/кс номерлы карары белән билгеләнгән «Казан» Халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте өчен 2019 елга ташландык суны (җир өсте агым сулары) чыгаруга озак вакытка исәпләнгән тарифларны үзгәртү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Тарифлар буенча федераль хезмәтнең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләп чыгару буенча методик күрсәтмәләрне раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы, «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суны чыгару өлкәсендә җайга салына торган тарифларны билгеләү регламентын раслау турында» 2014 елның 16 июлендәге 1154-э номерлы боерыклары нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә таянып, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2017 – 2019 елларга «Казан» Халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте өчен ташландык суны чыгаруга тарифлар билгеләү турында» 2016 елның 9 декабрендәге 10-36/кс номерлы карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2017 елның 17 ноябрендәге 10-35/кс номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырылган көннән соң 10 көн эчендә үз көченә керә.

Рәиснең беренче урынбасары А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
2018 елның 9 ноябрендәге 10-31/кс номерлы карары
2016 елның 9 декабрендәге 10-36/кс номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 9 ноябрендәге 10-31/кс номерлы карары редакциясендә) 1 нче кушымта

## Ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «Казан» Халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте өчен 2017 – 2019 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп, ташландык суны (җир өсте агым сулары) чыгаруга тарифлар

| т/б № | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме | Ташландык суны (җир өсте агым сулары) чыгаруга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2017 ел | | 2018 ел | | 2019 ел | |
| | | 2017 елның 1 гыйнварыннан алып 2017 елның 30 июненә кадәр | 2017 елның 1 гыйнварыннан алып 2017 елның 31 декабренә кадәр | 2018 елның 1 гыйнварыннан алып 2018 елның 30 июненә кадәр | 2018 елның 1 июленнән алып 2018 елның 31 декабренә кадәр | 2019 елның 1 гыйнварыннан алып 2019 елның 30 июненә кадәр | 2019 елның 1 июленнән алып 2019 елның 31 декабренә кадәр |
| | Лаеш муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Казан» Халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте | | | | | | |
| 1.1 | Халкы (тарифлар НДСны исәпкә алып күрсәтелгән)* | 11,88 | 12,13 | 9,70 | 9,70 | 9,54 | 9,54 |
| 1.2 | Башка кулланучылар (тарифлар НДСны исәпкә алмыйча күрсәтелгән) | 10,07 | 10,28 | 8,22 | 8,22 | 7,95 | 7,95 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын кулланалар

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тарифларны кабул итүне оештыру, тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
2018 елның 9 ноябрендәге 10-31/кс номерлы карары
2016 елның 9 декабрендәге 10-36/кс номерлы карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 9 ноябрендәге 10-31/кс номерлы карары редакциясендә) 2 нче кушымта

Ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы «Казан» Халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте өчен
2017 – 2019 елларга, календарь бүленештә күрсәтеп,
ташландык суны (җир өсте агым сулары) чыгаруга тарифларны җайга салуның озак вакытка каралган параметрлары

| № т/б | Салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык суны чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың исеме тариф төре | Ел | Операцияләр чыгымнарының башлангыч күрсәткече | Оперцияләр чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма кулланылышы |
| | | | мең сум | процент | процент | кВт·сәг./куб.м |
| 1 | «Казан» Халыкара аэропорты» акционер җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Ташландык суны (җир өсте агым сулары) чыгару | 2017 | 725,14 | 1 | - | 0,11 |
| | | 2018 | 746,37 | 1 | - | 0,11 |
| | | 2019 | 772,88 | 1 | - | 0,11 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының
тарифларны кабул итүне оештыру,
тикшерү һәм документлар белән тәэмин итү бүлеге